ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 17.12.2024 2086 **КАРАР**

2025 елга Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районында балалар
һәм яшьләр ялын оештыру турында

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2024 елда мәктәп һәм студент яллары чорында балалар һәм яшьләр ялын, савыктыруны, мәшгульлеген оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 елның 9 сентябрендәге 754 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республиикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру программасын расларга (1 нче кушымта).
2. 2025 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).
3. 2025 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район ведомствоара комиссия составын расларга (3 нче кушымта).
4. Балалар һәм яшьләрне ял итү оешмаларына кабул итү комиссиясе составын расларга (4 нче кушымта).
5. Сменаларны оештыручы - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетына лагерьларга юлламалар (путевкалар) бирү өчен гариза формасын расларга (5 нче, 6 нчы кушымта).
6. Муниципаль лагерьларда балалар һәм яшьләр ялы өчен ата-аналар түләвенең күләмен билгеләргә (7 нче кушымта).
7. Түбәндәге балаларының һәм яшьләренең ялын, сәламәтләндерүен оештырырга:

- гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы - 6,5 яшьтән. алып 18 яшькә кадәрге балалар;
- муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

- коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалары;

- кадет мәктәпләрендә һәм гомуми белем бирү училищеларында тәрбияләнүче - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- хроник авырулары булган ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсенең озатуында булган - 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- авыр тормыш хәлендә калган балалар, шул исәптән:

- ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган оешмаларда тәрбияләнүче балалар, опекун һәм тәрбиягә бала алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- инвалид һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлеге чикләнгән - 4 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаган, махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүче балалар:

- социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- девиант (җәмгыять өчен куркыныч) холыклы балалар һәм яшүсмерләр өчен ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендәге - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар;

- килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәмендә җиңә алмаган - 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар хәл итә алмый.;

- бала туу һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие алучы гаиләләрнең - 17 яшькә кадәр балалары;

- югары белем бирү оешмаларында белем алучы - 18 яшьтән 30 яшькә кадәрге студентлар;

- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операциясеуздырыла торган зонага командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаиләләренннән (гаилә әгъзаларына) булган балалар;

-махсус хәрби операциядә катнашу барышында инвалидлык алган гражданнар гаиләләренең балалары.

8. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (А.С. Балобанова):

8.1. гомуми белем бирү оешмаларында көндезге мәктәп яны лагерьларында сменалар эшен тәэмин итәргә, һәр лагерьда профилактик исәптә торучы яшүсмерләр, шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган һәм авыр тормыш хәлендә калган балалар (беренче сыйныфтан унынчы

сыйныф укучыларын кертеп) өчен барлык типтагы сәламәтләндерү лагерьларына мәҗбүри квота бирүне күздә тотарга;

8.2. гомуми белем бирү оешмалары базасындагы сменалар эшен хәрби-патриотик юнәлештә, хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре күрсәтмәләрен исәпкә алып, хәрби хезмәткә чакырылу яшенә җитмәгән егетләрнең көндезге мәктәп яны лагерьларында (беренче сыйныфтан унынчы сыйныф укучыларын кертеп) ялын һәм сәламәтләндерүне оештырырга;

8.3. каникуллар чорында барлык өстәмә белем бирү оешмаларының эшен тәэмин итәргә;

8.4. Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы һәм Алабуга муниципаль районының тарихи урыннары булган Алабуга музей-күргәзмә объектларына укучыларны алып баруны күздә тотып, туристик-экскурсия эшен гамәлгә ашырырга;

8.5. 2025 елнын 1 июненнән 2025 елның 30 августына кадәр балигъ булмаганнарның хокук бозуларын профилактикалау системасы субъектлары белән берлектә «Имин җәй-2025» операциясен уздырырга;

8.6. мөмкинлекләре чикле балаларны кимендә 35% җәлеп итәргә һәм ата-аналарын кертем түләүдән азат итәргә;

8.7. «Алабуга шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе белән берлектә (килешү буенча) кимендә 250 кешене, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган баланы, укудан тыш вакытта һәм каникуллар чорында шәһәр һәм район оешмаларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга;

8.8. балигъ булмаган гражданнарны җәйге чорда эшкә урнаштыру исемлекләрен төзергә;

8.9. Алабуга муниципаль районының авыл җирлекләрендә гомуми белем бирү оешмалары базасында хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар эшен оештырырга.

9. Алабуга муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү оешмалары җитәкчеләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- ял итү урыннарында балалар һәм яшьләрнең иминлеген саклау чаралар комплексын;

- ял итү урыннарында янгын куркынычсызлыгы, эш режимына санитария-эпидемиология таләпләрен үтәүне;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү урыннарында балаларның коену өчен билгеләнгән су объектларының су төбен водолазлар белән тикшерүне һәм чистартартуны;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү урыннарында килеп туган бәхетсезлек очракларыннан, тикшеренүләр алып барганда балаларны һәм яшьләрне ирекле иминләштерү эшен оештыруны;

- балалар һәм яшьләрнең ял итү урыннарын квалификацияле белгечләр, һөнәри әзерлек дәрәҗәсе булган педагогик кадрлар белән тәэмин итүне, тиешле вазифа буенча квалификация характеристикасында билгеләнгән таләпләргә туры килүне;

- сменалар барышында балаларны һәм яшүсмерләрне гигиеник тәрбияләү, наркоманияне, тәмәке тартуны профилактикалау, сәламәт

яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштырушы, физик тәрбия һәм чыныктыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрүне;

- балалар һәм яшьләрнең мәнфәгатьләрен һәм психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны эчтәлекле ял итү өчен шартлар тудыруны;

- Россия Федерациясе законнары нигезендә ял оештыруда эшкә урнашкан затларга, хөкем ителү һәм (яисә) җинаять эзәрлекләве факты булу яисә билгеле бер җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләвен туктату предметына алдан тикшерүләр үткәрүне оештыруны;

- балалар ял лагерьларын ачарга 14 көн кала, лагерь территориясен һәм аннан 50 метр зонада, шулай ук энтомологик күрсәткечләр булганда, сменалар арасында талпаннарга каршы эшкәртү үткәрүне;

- балалар сәламәтләндерү лагерьлары җитәкчеләрен һәм педагогик составны хезмәтне саклау, янгын-техник минимумы программалары һәм билгеләнгән тәртиптә барлык хезмәткәрләрне гигиеник әзерләү программалары буенча укытуны оештырырга;

- «Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына санитар-эпидемиологик таләпләр» СП 3.1/2.4.3648-20 нигезендә эшне гамәлгә ашырырга;

- 2025 елның 15 маена кадәр «Юный строитель» балаларны савыктыру лагере, «Лесная сказка» балаларны савыктыру лагере, «Космос» балаларны савыктыру лагере, «Радуга» шифаханәсе ЯАҖ каршындагы «Солнышко» балаларны савыктыру лагере, «Буревестник» спорт-савыктыру лагере паспортларын рәсмиләштерергә.

10. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы (И.В. Смирнов), «ЯЛ үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.М. Гарипова):

10.1. «Юный строитель» балаларны савыктыру лагере смена дәвамлылыгы - 21 көн (җәйге каникулларда), 7 көн (язгы каникулларда); «Лесная сказка» балалар савыктыру лагереның профильле сменалары дәвамлылыгы - 18 көн (җәйге каникулларда), 7 көн (язгы һәм җәйге каникулларда)

10.2. Беренче чиратта түбәндәге балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруны тәэмин итәргә, - авыр тормыш хәлендә булган балалар - ятим балалар, ата-ана каравын мәхрүм калган балалар;

- инвалид балалар;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, ягъни физик һәм (яки) психик үсешләрендә кимчелекләре булган балалар;

- кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген катастрофалар, табигать афәтләре корбаннары балалары;

- качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән булган балалар; экстремаль шартларда калган балалар; көч куллану корбаннары балалары;

- көч куллану корбаннары булган балалар;

- белем бирү оешмаларында девиант (иҗтимагый куркыныч) үз-үзен тотышына, махсус тәрбия, укыту һәм махсус педагогик якын килүне таләп итә торган аерым шартларга мохтаҗ булган балалар;

- тормыш эшчәнлеге барлыкка килгән шартлар нәтиҗәсендә объектив бозылган һәм мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән хәл ителергә мөмкин булган хәлләр нәтиҗәсендә бозылган балалар;

- килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәмендә җиңә алмаган балалар;

- бала туууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче 17 яшькә кадәрге балалар;

- социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдән булган балалар.

10.3. Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләренең ялын оештыруның иң яхшы вариатив программасына Республика конкурсында катнашырга;

10.4. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының «Балигъ булмаганнарга сәламәтләндерү һәм оешкан ял вакытында медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2018 елның 13 июнендәге 327н боерыгы нигезендә, шәһәр яны лагерьларының медицина җиһазлары, дару чаралары һәм медицина эшләнмәләре белән тәэмин итәргә;

10.5. Авыр тормыш шартларында булган юллама алган балалар, муниципаль һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары һәм коммерциячел булмаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары, көндезге (мәктәп яны) хезмәт һәм ял лагерьларында белем бирү оешмалары оештырган лагерьларда ял иткән балалар турында мәгълүмат бирүне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны куллану юлы белән һәм Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа операторы билгеләгән формат нигезендә тәэмин итәргә.

11. 2025 елның 1 июненнән 2025 елның 25 августына кадәрге чорда Алабуга муниципаль районы территориясендә «Яшүсмер - 2025» ведомствоара профилактик операциясен игълан итәргә.

12. Алабуга муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясенә:

12.1. «Яшүсмер – 2025» ведомствоара профилактик операциясен уздыруны тәэмин итәргә;

14.2. профилактик исәптә торучы балалар һәм яшүсмерләрнең, шулай ук социаль куркыныч хәлдә калган балаларның җәйге ялын мониторинглауны гамәлгә ашырырга һәм белешмәләрне 2025 елның 1 июненә кадәр балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Республика комиссиясенә җибәрергә;

12.3. профилактик исәптә торучы балалар һәм яшүсмерләр ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген 100% оештыруны тәэмин итәргә;

12.4. балигъ булмаганнар профилактик исәптә торучы, шулай ук социаль куркыныч хәлдә булган һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларның, шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның, вакытлыча һәм даими эшкә урнашуын мониторинглауны гамәлгә ашырырга;

12.5. балаларның җәйге ялын оештыру буенча эш нәтиҗәләрен Алабуга муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның

хокукларын яклау комиссиясе утырышында, «Яшүсмер – 2025» ведомствоара профилактик операциясе йомгаклары ясарга һәм аларны балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә 2025 елның 20 сентябренә кадәр җибәрергә.

13. «Алабуга халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (Ю.Л. Демина) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

13.1. 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан тыш вакытта һәм каникулда вакытлыча эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга;

13.2. җәйге чорда балигъ булмаган балаларны хокук бозуларны профилактикалау системасы субъектларында һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә профилактик исәптә торган балигъ булмаган гражданнарны беренче чиратта эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә;

13.3. балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытта эшкә урнаштыруны оештыру буенча 350 кеше исәбеннән шартнамәләр төзергә.

14. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

14.1. балалар һәм яшьләрне сәламәтләндерү эшен оештыру буенча 2025 елга җирле бюджетта каралган расланган акчалар чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә;

14.2. 2025 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан гомуми суммада 28 887 000,10 сум бүлеп бирелгән субсидияләр исәбеннән балалар һәм яшьләрнең ялын финанслауны гамәлгә ашырырга;

14.3. чыгым йөкләмәләрен үтәү максатларында җирле үзидарә органнары акчалары исәбеннән финанслауның кимендә 1 процентын күздә тотарга.

15. Лагерьларда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен ата - аналар түләве түбәндәге категорияләрдән алынмый дип билгеләргә:

- авыр тормыш хәлендә булган балалар - ятим балалар, ата-ана каравын мәхрүм калган балалар;

- инвалид балалар;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, ягъни физик һәм (яки) психик үсешләрендә кимчелекләре булган балалар;

-кораллы һәм милләтара конфликтлар, экологик һәм техноген катастрофалар, табигать афәтләре корбаннары балалары;

- качаклар һәм мәҗбүри күченүчеләр гаиләләреннән булган балалар; экстремаль шартларда калган балалар; көч куллану корбаннары балалары;

- көч куллану корбаннары булган балалар;

- белем бирү оешмаларында девиант (иҗтимагый куркыныч) үз-үзен тотышына, махсус тәрбия, укыту һәм махсус педагогик якын килүне таләп итә торган аерым шартларга мохтаҗ булган балалар;

- тормыш эшчәнлеге барлыкка килгән шартлар нәтиҗәсендә объектив бозылган һәм мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәме белән хәл итәлергә мөмкин булган хәлләр нәтиҗәсендә бозылган балалар;

- килеп туган хәлләр нәтиҗәсендә һәм әлеге хәлләрне мөстәкыйль рәвештә яисә гаилә ярдәмендә җиңә алмаган балалар;

- бала тууга һәм тәрбияләүгә бәйле рәвештә айлык пособие алучы гаиләләрдә тәрбияләнүче 17 яшькә кадәрге балалар;

- социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслашкан оешмаларда тәрбияләнүчеләр;

- социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар;

- иҗади сәләтле һәм социаль актив балалардан һәм палатка тибындагы лагерьларда хәрби-патриотик тәрбиягә юнәлдерелгән сменаларда катнашучылардан;

- хезмәт һәм ял лагерьларында гомуми белем бирү оешмаларында белем алучылардан;

- хроник авырулары булган, шул исәптән аларны озата баручы ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсеннән;

- махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрбиләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнар, махсус хәрби операциясеуздырыла торган зонага командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның югарыда күрсәтелгән категорияләренең гаиләләренннән (гаилә әгъзаларына) булган балалар.

16. «Алабуга балалар йорты» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә (Р.И. Зарипов) мәктәп-интернатларның үз сәламәтләндерү лагерьларында, шулай ук «Дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактлар ярдәмендә шәһәр яны лагерьларында балалар йорты тәрбияләнүчеләренең ялын оештыруны тәкъдим итәргә.

17. «Алабуга урманчылыгы» дәүләти казна оешмасына (А.К. Усманов), Федераль дәүләт бюджет учреждениесенә «Түбән Кама» милли паркын (А.К. Усаманов) бөтен җәйге сәламәтләндерү кампаниясе дәвамында урман-техник чаралар үткәрү, аста үсүче һәм коры ботакларны, куакларны кисү, яшь үсентләрне кисү, үлән чабу, шәһәр читендәге балалар белем бирү учреждениесе тирәсендә 500 метр радиуста коры чыбык һәм чүп-чар чыгаруны, чистартуны тәкъдим итәргә.

18. Казан Федераль Университетының Алабуга филиалына (Е.Е. Мерзон), «Алабуга политехника көллияте» урта һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесенә (С.В. Соколова), «Алабуга медицина училищесы» урта һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесенә (Н.А. Ушакова), «Алабуга мәдәният һәм сәнгать көллияте» урта һөнәри белем бирү дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенә (Л.Н. Рыбакова), «Синергия» һөнәри көллияте» ДҺББУ (Ф.Н. Рузанов) каникул чорында

студентлар ялын, сәламәтләндерүне һәм үзмәшгульлек итүне оештыруны тәкъдим итәргә.

19. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә (А.С. Балобанова), Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторына (И.В. Смирнов), Казан Федераль Университетының Алабуга филиалына (Е.Е. Мерзон), «Космос» балаларны савыктыру лагерена, «Радуга» шифаханәсе ЯАҖ каршындагы «Солнышко» балаларны савыктыру лагерена түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

19.1. лагерьның исемен, вазифасын, смена дәвамлылыгын (срокларын) күрсәтеп, шәһәр яны ял лагерьлары хезмәткәрләренә медицина тикшерүенә юнәлешләр бирүне тәэмин итәргә;

19.2. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының 2018 елның 13 июнендәге «Сәламәтләнү һәм оешкан ял чорында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 327 номерлы боерыгы нигезендә, лагерьларның медицина кабинетларын кирәкле медицина җиһазлары, дару чаралары һәм медицина билгеләнешендәге әйберләр белән тәэмин итәргә;

19.3. балаларның ялы һәм аларны савыктыру оешмаларында медицина кабинетларын лицензияләү чараларын күрергә.

20. Россия Эчке эшләр министрлыгының Алабуга муниципаль районы буенча бүлегенә (О.М. Камалюков) балаларны сәламәтләндерү учреждениеләренә йөртүне һәм кире кайтаруны оешкан төстә башкара торган транспорт чараларын юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясенең патруль автомобильләре белән озата баруны тәкъдим итәргә.

21. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторына (И.В. Смирнов), «Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Җәй» балалар һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә үз вакытында барлык типтагы лагерьларны ачу графиклары, балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру һәм йомгаклау финанс хисабы буенча оператив мәгълүмат тапшыру өчен җаваплы кешене билгеләргә.

22. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

23. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Н.Д. Курамшинга йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025

Э.Р. Әхмәдиева

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
20___елның “___ ___номерлы
карарына 1  нче кушымта

# 2025 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балалар  һәм яшьләр ялын оештыру программасы

## ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2025 елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балалар һәм яшьләр ял итүен оештыру программасы (алга таба- Программа) |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп төзүчесе (эшләүчесе) | Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы |
| Программаның төп башкаручылары | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты;<br>«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ,<br>«Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ,<br>Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы,<br>«Алабуга шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ (килешү буенча);<br>Алабуга муниципаль районы буенча Россия ЭЭМ ББЭБ һәм ПУУ (килешү буенча);<br>Роспотребнадзор идарәсенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Алабуга шәһәре һәм Алабуга районында территориаль бүлеге (килешү буенча)<br>Алабуга районында һәм Алабуга шәһәрендә «Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУ (килешү буенча) |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле шартлар тудыру.<br>Бурычлар:<br>-балалар һәм яшьләрнең төрле ял рәвешләрен, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;<br>-сәләтле балаларны ачыклау, шулай ук фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне яклау системасын булдыру;<br>-балалар һәм яшьләр җәмәгать оешмаларына, волонтерларга ярдәм итү, ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм итү;<br>-балалар авыруыннан һәм инвалидлык профилактикасына карата чаралар уздыру;<br>- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>- авыр тормыш шартларында булган балалар балалар җәмгыяте белән нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм интеграция булдыру;<br>- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын каникул чорында ял белән тәэмин итү;<br>- балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү;<br>-тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм имин булмаган балалар проблемаларын хәл итү;<br>- ял оешмаларын персоналлар белән тулысынча тәэмин итү. |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2025 ел |
| Программаны финанслау | 2025 елга Программаны финанслауның гомуми күләме **39 531,5 мең сум** тәшкил итә, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасы бюджетыннан ял һәм сәламәтләндерүне оештыруга **28 887,1 мең сум** субсидия;<br>- ата-аналар акчасы **8 990,0 мең сум;**<br>**-** башка акчалар **1 365,3 мең** сум;<br>**-** җирле бюджет **289,1 мең сум.**<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләштерелергә) тиеш. |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Иҗади яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен стационар һәм палатка лагерьларында профильле сменалар оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял лагерьларында сменаларны оештыру.<br>3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменалар оештыру.<br>4. Хезмәт һәм ял лагерьларын оештыру.<br>5. Балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыру.<br>6. Хокук бозуларны профилактикалау белән бәйле чаралар оештыру.<br>7. Авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен Татарстан Республикасында стационар һәм палатка тибындагы лагерьларда сменалар оештыру. |
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Барлык программа чаралары нәтиҗәләре буенча чагылган сәламәтләндерү эффектының 90 проценттан да ким булмаган дәрәҗәсенә ирешү.<br>Гамәлгә ашырылган чараларның (балаларның ялын, әйдаманнар мәктәпләрен, семинар-тренингларны, профильле сменаларны, палаткалы лагерьлар оештыручыларны әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү программалары) сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге. |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

## 1. 2025 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының балалар һәм яшьләрнең ял итү программасын гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика

Җәйге каникуллар чоры мәктәп укучыларының һәм студентларның еллык буш вакытларының шактый өлешен тәшкил итә. Ялны оештыру буеча ведомствоара комиссиясе әгъзалары һәм профилактика субъектлары арасында төп мәсьәлә – балалар һәм яшьләрнең имин, дөрес ялларын оештыру. Балалар һәм яшьләрнең каникул ялын, сәламәтлеген ныгытуны һәм мәшгульлекне уңай оештыру, психолого-педагогик, методик һәм җитәкчелек итү буенча гомуми бер мәсьәләләр комплексының чишелешен күздә тота. Программаның сәламәтлекне ныгытуга юнәлдерелгән чараларын гамәлгә ашыруда төрле типтагы 50 лагерь катнаша, аеруча:

*4 шәһәр чите стационар савыктыру лагере (2-савыктыру-ял итү учреждениесе (лагерь), 1-балалар савыктыру лагере, 1-спорт-савыктыру лагере);

*40 көндезге мәктәп яны лагере (март-апрель, июнь-июль);

* 10 мәктәп яны хезмәт һәм ял лагере (июнь);

* 1 «Радуга» шифаханәсе ЯАҖ каршындагы «Солнышко» балалар савыктыру лагере ;

* көндезге «ИнтелЛето» профильле лагерь;

«Йолдызлык» МҮҮ (июнь-июль) базасында көндезге лагерь.

### 2025 елга балалар һәм яшьләрнең ял күрсәткечләре

| Лагерьлар категорияләре | Ял иткән балалар саны |
|---|---|
| Мәктәп яны лагере (7 көнлек) | **200** |
| Мәктәп яны лагере (21 көнлек) | **1690** |
| Мәктәп яны хезмәт һәм ял лагере | **200** |
| Авыр тормыш шартларында калган балаларны сәламәтләндерү | **300** |
| «Юный строитель» БСЛ (төп) | **360** |
| «Юный строитель» БСЛ (профильле) | **234** |
| «Лесная сказка» БСЛ (төп) | **153** |
| «Лесная сказка» БСЛ (профильле) | **80** |
| «IT-территория» | **92** |
| ИнтелЛето | **130** |
| «Буревестник» ССЛ җәйге физика-математика мәктәбе | **80** |
| Буревестник» ССЛ (ДХР балалары) | **36** |
| «Буревестник» ССЛ (студентлар) | **518** |
| «Космос» БСЛ | **932** |
| «Радуга» балалар савыктыру лагере | **2389** |
| «Яшел утрау» ДОЛ палаткалы лагере (Баулы районы) | **25** |
| Растим патриотов» | **41** |

| | |
|---|---|
| «Дети галактики» | **15** |
| «Сэлэт» | **110** |
| **БАРЛЫГЫ:** | **7585** |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында» 2020 елның 4 апрелендәге 346 номерлы карарының 2 пункты нигезендә юлламалар «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә сатып алына.

Сәламәтләндерү оешмасына юллама алу хокукына, авыр тормыш хәлендә калган баланы кертеп, 7-15 яшьлек балалар ия, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 13 декабрендәге 1023 номерлы карары кысаларында «Җәй» республика үзәге» Дәүләт бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторы тарафыннан юллама алучының яшәү урынына карап дәүләт хезмәте күрсәтелә.

Җәйге чорда балигъ булмаганнар профилактик хисапта «Дети галактики» профильле лагерена җибәреләчәк.

Күпкатлы йортларның тәрәзәләреннән кечкенә балаларның егылып төшү очраклары ешаю сәбәпле, Алабуга муниципаль районы территориясендә ел саен 1 майдан алып 31 августка кадәр дәвам итәчәк, «Сак булыгыз! Балалар һәм ачык тәрәзә!» акциясе уздырыла. Бу акция кысаларында тематик буклетлар, видеосюжетларәзерләнә, балалар поликлиникасы нигезендә кечкенә балалы гаиләләр өчен аңлату эшләре алып барыла. Профилактика үтүче барлык субъектларга да казалардан саклау максатыннан чыгып, истәлекле мәгълумат белешмәлекләре бирелә. ББЭБ (балигъ булмаганнар эше бүлеге), ББЭК (балигъ булмаганнар эше комиссиясе) белгечләре һәм муниципаль бюджет учреждениесенең «Форпост» яшьләр үзәгенең активистлары хәрәкәте тарафыннан тәрәзәдән кечкенә балалар егылып төшү очракларын кисәтү максатыннан чыгып, шәһәр тулай тораклары буйлап ведоствоара рейдлар оештырылар.

Җәйге каникуллар чорында балаларның ялында куркынычсызлык кагыйдәләренә төшендерү, рөхсәт ителмәгән урыннарда су керү ярамаганлыгын кисәтү максатыннан чыгып, 1 июньнән алып 31 августка кадәр кадәр «Су буеда сәламәт һәм куркынычсыз ял!» акциясе уздырыла. Су буйларында каралган график буенча ББ ЭК һәм хокук яклау комиссиясе, массакүләм мәгълумат чаралары вәкилләре һәм ГТХМ хезмәткәрләре катнашында ведомство ара рейдлар оештырылачак.

Шулай ук, Алабуга муниципаль районы территориясендә «Истә тотыгыз!», «Янгынны кисәтү сүндерүгә караганда җиңелрәк!» акциясе

уза. Ул шәһәр халкына янгын чыгуны булдырмау кагыйдәләрен төгәл үтәргә, истә тотарга ярдәм итә.

Ел саен Алабуга муниципаль районы территориясендә ведомствоара профилактик операциясе «Яшүсмер» уздырыла. Ул 3 этаптан тора:

1. «Үзмәшгульлек» 01.06-20.06.2025
2. «Каикуллар» 05.07-25.07.2025
3. «Гаилә» 01.08-25.08.2025

Җәйге каникуллар чорында юлларда балаларның куркынычсызлыгын тәэмин итү максаты белән 15.05-15.06.2024 кадәр ЮХИДИ (юл хәрәкәтләре иминлеге дәүләт инспекциясе) белән берлектә «Машина йөртүчеләр, сак булыгыз! Юлларда балалар!» акциясе уздырылачак. Муниципаль районның белем бирү системасы тарафыннан җәйге сәламәтлендерү кампаиясе чорында 7 яшьтән 18 яшькә кадәр булган 1820 баланың ялын тәэмин итүне үз өстенә ала. Мәктәпяны хезмәт һәм ял лагерьләре 200 ләп балага каралган. Мәктәпяны лагерьләрендә 21 көнлек, ә хезмәт һәм ял лагерьләрендә 18 көнлек сменалар каралган. Лагерьләрнең эш сәгате көндезге йокысыз, шәһәр җирлегендә 08.00 дән 17.00 кә кадәр, авыл җирлегендә 08.00 дән 15.00 кә кадәр булачак.

Алабуга институты (КФУ) җирлегендә 2024 елның 15 июненнән 2025 елның 5 июленә кадәр 7-15 яшьлек балаларның «ИнтелЛето» интеллектуальсавыктыргыч көндезге лагеренең эше планлаштырылган. Әлеге лагерьдә көннең беренче яртысында белем бирү циклына:интеллектуаль тренингларга, информатика, физика, математика һәм башка фәннәр буенча шогыльләргә багышланган. Балалар төрле түгәрәкләрдә үзләрен дизайнер, авиаконструктор буларак сынап карыйлар. Көннең икенче яртысы төрле спорт һәм тәрбияви чараларга багышланган. Лагерьда студентлар практика узачаклар.

Алабуга муниципаль районы территориясендә (һәр сменасы 21 көн булган) җәйге 3 сменалы «Юный строитель» балалар савыктыру лагере, «Радуга» шифаханәсе ЯАЖ каршындагы «Солнышко» балалар савыктыру лагере, «Буревестник», 18 көнлек 4 сменалы «Лесная сказка» БСЛ, 21 көнлек 4 сменалы «Космос» балалар савыктыру лагере һәм 21 көнлек 3 сменалы студентлар савыктыргыч лагере «Буревестник» - 12 көн эшлиячәк.

Җәйге чорда яшүсмерләрне һәм яшьләрне эш белән тәэмин итү иң төп мәсьәлә булып тора. Бу максат белән мәктәпләрдә территорияне төзекләндерү белән шогыльләнүче хезмәт бригадалары оештырылачак. Мәшгульлек үзәге линиясе буенча 350 яшүсмерне хезмәт белән тәэмин итү каралган. Моның өчен 14-18 яшьлек балигъ булмаган яшүсмерләрне җәйге каникул вакытында эш белән тәэмин итү мөмкинлеге булу турында мәгълумат тарату оештырылачак.

Шулай ук, шунысын да өстәргә кирәк, җәйге чорда көндезен һәм кичен Алабуга муниципаль районы территориясендә :

-22 спорт мәйданчыгы;

-5 йортяны мәйданчыгы;

-11 яшүсмерләр клубы һәм МБУ МҮ «Барс» «Шатлык остаханәсе» проекты кысаларында 5 яшәү урыны мәйданчыгы эшләячәк.

Эш тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бу мәйданчыклар яшүсмерләр өчен дә, аеруча, ата-аналар өчен дә бик кирәк.

«Юный строитель» балалар савыктыру лагере, «Лесная сказка» балалар савыктыру лагере, «Космос» балалар савыктыру лагере, «Радуга» шифаханәсе ЯАҖ каршындагы «Сллнышко» балалар савыктыру лагере, «Буревестник» балалар савыктыру лагерьләрендә лицензияле медицина кабинетлары һәм медицина ярдәме күрсәтүче шәфкать туташы эшләячәк. Шәһәр мәктәпяны лагерьләрендә медицина ярдәмен мәктәп шәфкать туташлары, авылларда-фельдшер-акушер пунктларындагы медицина хезмәткәрләре күрсәтәчәк.

Балаларны су коендыруны оештырганда имин йөзү өчен шартлар тәэмин итү планлаштырыла: «Космос» балалар савыктыру лагеренда ял итүче балалар медицина хезмәткәре һәм инструктор карамагындагы шифаханә бассейнында гына су коеналар. Барлык балалар белән коену алдыннан инструктаж үткәрәләр, суда инструктаж өчен дәфтәргә язу өчен үз-үзеңне тоту кагыйдәләре аңлатылачак.

Шәһәр һәм район китапханәләрендә балалар өчен тематик чаралар, уеннар, кызыксынучаннар клубы оештыру, конкурслар, викториналар уздыру планга кертелгән. Бу чорда шәһәр һәм авыл китапханәләре, аеруча мәктәп, балалар бакчалары китапханәләре белән тыгыз элемтәдә эшләргә тиеш.

Моның белән бәйле рәвештә тулаем һәм эзлекле дәүләт сәясәте бала ялын оештыру системасы тармагында бик актуаль. Аның төп максаты-балаларны ял иттерү һәм савыктыру өлкәсендә сыйфатлы хезмәт күрсәтеп, халыкның канәгатьлеген арттыру. Аңлашылганча, бу балаларның иҗади потенциалын үстерү, сәламәтлеген, куркынычсызлыгын ныгыту өчен төрле чаралар күрү, физкультура, спорт, туризм белән шогыльләнергә тарту, сәламәт һәм дөрес туклау, сәламәтлек саклау күнекмәләрен ныгыту, әйләнә-тирә мохиттә яшәү өчен санитар-гигиеник һәм санитар-эпидемиологик таләпләргә туры килерлек итеп, уңай шартлар тудыру өчен хәзергесе вакытта бик күп көч таләп итә.

## 2. Программаның төп максатлары, бурычлары, аны гамәлгә ашыру вакыты (сроклары) һәм этаплары.

Программаның максаты-балалар һәм яшьләр савыктыру ялын, каникуллар вакытындагы шогылен дөрес, уңай һәм файдалы итеп оештыру өчен тиешле чараларны күрү. Шушы максатка ирешү өчен түбәндә куелган мәсьәләләрне чишү таләп ителә:

Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерүнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәкле шартлар тудыру.

Бурычлар:

-балалар һәм яшьләрнең төрле ял рәвешләрен, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;

-сәләтле балаларны ачыклау, шулай ук фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне яклау системасын булдыру;

-балалар һәм яшьләр җәмәгать оешмаларына, волонтерларга ярдәм итү, ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм итү;

-балалар авыруыннан һәм инвалидлык профилактикасына карата чаралар уздыру;

- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;

- авыр тормыш шартларында булган балалар балалар җәмгыяте белән нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм интеграция булдыру;

- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын каникул чорында ял белән тәэмин итү;

- балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү;

-тормыш эшчәнлеген яхшырту һәм имин булмаган балалар проблемаларын хәл итү;

- ял оешмаларын персоналлар белән тулысынча тәэмин итү.

Программа 2025 ел дәвамында гамәлгә ашырылачак.

## 3. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

2025 елга Программаны финанслауның гомуми күләме **39 531,5 мең сум** тәшкил итә, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы бюджетыннан ял һәм сәламәтләндерүне оештыруга **28 887,1 мең сум** субсидия;
- ата-аналар акчасы **8 990,0 мең сум;**
- башка акчалар **1 365,3 мең** сум;
- җирле бюджет **289,1 мең сум.**

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертергә (төгәлләштерелергә) тиеш.

## 4. Программаны гамәлгә ашыру механизмы.

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр сәясәтен үстерү секторына Программада катнашучыларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру һәм координацияләү өчен җаваплы башкарма хакимият органы булып тора, ул тармак учреждениеләре, предприятиеләр җитәкчеләре һәм башка оешмалар белән берлектә:

-Программаны гамәлгә ашыру механизмына, аңа тотылачак чыгымнар күләменә, Программага кертелгән чаралар исемлегенә һәм тәртибенә аныклык кертә;

-максатлы индикаторлар исемлеген һәм кварталларга бүленешен аныклый;

